УДК 821.512.145

*А.М. Сафина*

# ӘДӘБИ КҮРЕНЕШ БУЛАРАК МИЛЛИ ХАРАКТЕР

Значимость данной работы состоит в том, что она раскрывает представление о роли и значении национального характера как литературоведческой категории. Анализируются и осмысливаются различные взгляды литературоведов на проблему национального характера.

**Ключевые слова:** национальный характер, литература, художественный характер, литературовед

Хәзерге чорда җәмгыятьнең үсеш шартлары, иҗтимагый мөнәсәбәтләр, мәдәният һәм фән-техника өлкәсендәге үзгәрешләр халыкның борынгы тамырларына, тарихи үткәненә, йолаларына, гореф-гадәтләренә, диненә һәм хәзерге тормыштагы ролен, урынын аңлауга игътибарны арттыра. Санап үтелгәннәрне ачыкларга милли хис, милли тойгы, милли аң, милли характер ярдәм итә. Милли хисләр һәм милли аң конкрет эшчәнлекне тудыра, ә милли характер шушы эшчәнлекнең сыйфатын билгели. Милли характер, кешенең конкрет юнәлештәге эшчәнлегенең нәтиҗәсе буларак, фәкать милли хисләр, милли мәнфәгатьләр турында уй-фикер йөртү аша гына формалаша ала. Милли характер – реаль күренеш, ул чынбарлыкның үзендә, кешеләрнең фикерләү ысулында, телендә, сәнгатендә, йолаларында, әйләнә-тирәдәге күренешләргә мөнәсәбәтендә чагыла.

Мәкаләдә төп нигез итеп алынган *милли характер* төшенчәсенең асылын, төзелешен, үзенчәлеген матур әдәбият мисалында ачыклау максаты куелды. Милли характерның әдәбияттагы урынын ачыклауга зур урын бирелгәнлектән, әдәбиятта характерның роленә дә тукталып китү урынлы булыр. Әдәбиятта характер матур әдәбиятның төп хасияте, язучының сурәтләү объекты төсендә карала. «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә характер төшенчәсе: «индивидуаль конкретлык белән, әмма шул ук вакытта тулы итеп тасвирланган кеше образы; аның иҗтимагый-тарихи шартлар формалаштырган характер сыйфатлары, үз-үзен тотышында, эш-хәрәкәтендә, уй-кичерешләрендә, сөйләшендә чагылган эчке дөньясы, аңа гына хас үзенчәлекләре», – дип ассызыклана [Әдәбият белеме…, б. 230]. Чөнки әдип, үз алдына куелган идея-эстетик бурычтан чыгып, характер тудыра, аңарда теге яки бу үзенчәлекле сыйфатларны туплый. Галим, татар әдәбияты белгече Ф. Хатипов әдәби характерны «герой табигатенә, холык-фигыленә хас үзенчәлекле билгеләр җыелмасы» дип ассызыклый [Хатипов, б. 157]. Әдәбияттагы характерны күренекле рус әдәбияты белгече Л. Тимофеев: «Характер – язучы тарафыннан

эстетик нормаларга туры китереп үзгәртелгән, тарихи шартларга тәңгәлләштереп әсәрдә сурәтләнгән кеше тибы, аның үз-үзен тотышы (эш-хәрәкәтләре, фикерләре, кичерешләре)», – дип аңлата [Тимофеев, с. 152].

Әдәби характер турында әйтелгән фикерләрдән чыгып, түбәндәге нәтиҗәне ясарга мөмкин: әдәби характер – гомумилек (барлык кешеләрдә дә очрый торган уртак сыйфатлар) һәм индивидуальлек (аерым шәхестә генә чагыла торган үзенчәлекләр) кушылуы, объективлыкның (кеше тормышының социаль-психологик чынбарлыгын прототибы аша күрсәтү) һәм субъективлыкның (авторның прототипка мөнәсәбәтен, бәясен күрсәтү) берләшүе. Димәк, әдәби характер, сәнгатьтә «яңа чынбарлык», реаль кеше тибын гәүдәләндерүче, сәнгатьчә «иҗат ителгән» шәхес буларак, тормышның идеологик ягын сурәтләүче вазифасын башкара.

Әдәби характерны ачуда, әдәбият галимнәре фикеренчә, тышкы, эчке, сюжет-композиция ысуллары файдаланыла. Тышкы ысул белән әдәби характер тудырганда автор бәяләмәсе, башка геройларның бәяләмәләре, әйләнә-тирәне, табигатьне, яшәү шартларын тасвирлау, диалог кебек алымнар кулланыла. Автор бәяләмәсе алымы әдәби характерны ачуда аеруча зур роль уйный. Әдәбият галиме М. Бахтин әсәрдә автор бәяләмәсенең әһәмиятен герой характерының һәрбер сыйфатын, тормышында, уй-кичерешләрендә булган һәрбер вакыйганы авторның җентекләп сурәтләвендә күрә [Бахтин, с. 9]. Әдәби характерны ачуда башка геройлар бәяләмәсе алымы, С. Остудина фикеренчә, геройның характер сыйфатларын аңларга булышып кына калмый, шулай ук бәяләмә бирүче герой характерын ачарга да ярдәм итә [Остудина, с. 43].

Эчке монолог, аң агышы, фикер, тойгы, омтылыш, кичереш, герой сөйләме, көндәлек, хат, әдәби детальләр кебек алымнар да әдәби характерны ачуда мөһим роль уйныйлар. Аң агышы алымының әдәби характерны ачудагы үзенчәлегенә игътибар итеп, В. Пэшко бу алымның әһәмиятен геройның рухи байлыгын ачуында саный. Аның фикеренчә, аң агышы алымы бу вакытта геройның психологик халәте көзгесе ролен үти [Пэшко, с. 45].

Әдәби характерны формалаштыруда сюжет сызыкларын, экспозицион материалларны, геройларның эш-гамәлләрен ачыклау кебек алымнар әһәмиятле урын алып торалар. Алар сюжет сызыгында характерны башлангыч ноктасыннан алып китеп, нинди карашларда, нинди сәбәп-йогынтылар тәэсирендә формалашуын тасвирлап бирүгә һәм формалашкан характерларны ачыклауга ярдәм итәләр.

Экспозицион материал әдәби характерны ачуда да зур роль уйный. Чөнки ул укучыны герой белән таныштырып, танышудан беренче тәэсир тудыруга булыша. Әдәбият галимәсе Л. Гинзбург укучыны беренче мәртәбә герой белән таныштыруны «әсәрнең алдагы төзелешен оештырырга юнәлдерелгән индекс» дип атый

[Гинзбург, с. 35]. Шулай итеп, *характер* төшенчәсе төрлечә ачылса да, төп вазифасы бер үк булып кала.

Матур әдәбият дөньяны танып белү, кешеләргә тормышны аңлатып бирү, идея-рухи яктан тәрбияләү максатына хезмәт итә, тормышны сурәтләр ярдәмендә чагылдыра. Ул кешеләрнең иҗтимагый тормышын да, шулай ук аларны чолгап алган табигать күренешләрен дә милли, «җирле» формада гәүдәләндерә. Рус язучысы Н.Г. Чернышевский моны түбәндәгечә аңлата: «Әгәр дә әсәрдә хәрәкәт итүче персонажлар милли яктан характерланмыйлар икән, алар чынбарлыктан һәм дөреслектән ерак торалар булып чыга» [Чернышевский, с. 129].

Әдәбиятта әдәби характер милли характер проблемасын ача. Чөнки матур әдәбиятта әдәби характерның милли сыйфатлары, фәнни яктан өйрәнүгә караганда, тирәнрәк һәм күпкырлырак итеп сурәтләнә. Бу – образларны үсештә һәм тарихи-социаль контекстта тикшерергә, матур әдәбиятта милли типларның күптөрлелеген, аларның сыйнфый табигатен һәм тарихи үсешен күрергә ярдәм итә. Әдәбиятта милли характер кешенең эчке дөньясын, аның объектив чынбарлыгын, кешеләр һәм җәмгыять белән үзара мөнәсәбәтен ача.

Матур әдәбиятта милли характер – язучының дөньяга карашын, реалистик һәм эстетик критерийлар күзлегеннән объектив чынбарлыкны образлы эмоциональ чагылдыруы. Әдәбиятта милли характер икегә бүленеп карала: сәнгать әсәре героеның милли характеры һәм сәнгати образлар тудыручының милли характеры. Сәнгать әсәре героеның милли характеры – милли чынбарлык үзенчәлегенең турыдан-туры чагылышы. Ул геройның хисләрендә, уйларында, мәнфәгатьләрендә һәм конкрет эшләрендә чагылып, аны иҗат итүче әдип тарафыннан тудырыла.

Милли характерның асылы табигый-климатик һәм биологик-соматик факторлар йогынтысында тарихи, социаль-икътисади һәм рухи үсеш юлында формалашкан милләтнең типик ныклы сыйфатлары җыелмасы буларак ачыла. Ул милләтнең рухын һәм үзенчәлеген, аның менталитетын, гадәтләрен, зәвыгын күрсәтә, Милли характер үз-үзеңне тотуда, шәхси аралашуларда, традицияләрдә, гореф-гадәтләрдә һәм тормыш образында күренә.

Милли характерны өйрәнгәндә рухи дөньяның кешелекне гасырлар дәвамында уйландырып килгән әхлакый-фәлсәфи һәм социаль проблемалары игътибарга алына. Әхлакый-фәлсәфи проблемалар матур әдәбиятта чагылыш таба. Матур әдәбиятта милли характер җәмгыятьнең тарихи вакыт эчендәге үсеше һәм милли тарих белән бәйләнеше аша сурәтләнә. Рус әдәбият белгече Н. Воробьева да үзенең хезмәтендә әдипнең, үзе яшәгән һәм иҗат иткән милли эстетик дөнья күзлегеннән чыгып, милли характерны сурәтләвенә тукталып китә [Воробьева, с. 162–185]. Матур әдәбият, геройны конкрет эшләрендә һәм

гамәлләрендә сурәтләп, үз тарихының төрле этапларында үзгәрүен күзәтеп, милли характерны ныклап өйрәнергә мөмкинлек бирә. Милли характерны сәнгать әсәрләрендә сурәтләү халыкка үзенең яшәешен аңларга булыша.

Әдәби әсәрләрдәге милли характер аерым кеше шәхесен сурәтли, аның үзенчәлеген, психикасын, дөньяга карашын күрсәтә. Милли характер шәхеснең эчке психологик дөньясында, аерым сыйфатлар җыелмасында чагыла. Милли характерның асылы күпкырлы һәм күптөрле, шуңа да ул һәрбер чорда яңача ачыла.

Халыкның әхлакый сыйфатлары, намусы, яшәү рәвеше, күркәм традицияләре, гореф-гадәтләре аның әдәбиятында тупланып килә. Әхлакый-фәлсәфи проблемалар матур әдәбиятта чагылыш табуга игътибар итеп, милли характерның асылын, төзелешен, үзенчәлеген матур әдәбият мисалында тикшердек. Матур әдәбият дөньяны танып белү, кешеләргә тормышны аңлатып бирү, идея-рухи яктан тәрбияләү максатына хезмәт итә, тормышны сурәтләр ярдәмендә чагылдыра. Әхлакый-фәлсәфи проблемалар матур әдәбиятта геройның һәм әдипнең милли характерлары аша ачыла. Әдәбиятта милли характер кеше һәм җәмгыять белән үзара мөнәсәбәтен ачып, кешенең эчке дөньясын, аның объектив чынбарлыгын яктырта.

**Әдәбият**

Әдәбият белеме сүзлеге / төз А. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 239 б.

*Бахтин М.М.* Эстетика словесного творчества. М.: Искусства, 1986. 445 с.

*Воробьева Н.Н.* Принцип историзма в изображении характера: классическая традиция и советская литература. М.: Наука, 1978. 264 с.

*Гинзбург Л.Я.* О литературном герое. Л., 1979. 222 с.

*Остудина С.В.* Особенности построения характера в романе Г. Бёлля «Групповой портрет с дамой» // Проблема характера в зарубежных литературах. Свердловск, 1992. С. 43–53.

*Пэшко В.Е.* Взаимохарактеристики и внутренняя речь как характерологические средства // Проблема характера в зарубежных литературах. Свердловск, 1985. С. 43–45.

*Тимофеев Л.И.* Основы теории литературы. М.: Просвещение, 1976. 448 с.

*Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе: югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студ. өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2000. 351 б.

*Чернышевский Н.Г.* Полное собрание сочинений: в 15 т. Т. 12. М.: Гослитиздат, 1949. 700 с.

***Сафина Алия Мәгъсүм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге фәнни хезмәткәре*